КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Калатау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

08.09.2022 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына таянып, 2022 елның 8 сентябрендә узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Калатау торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- ТР Саба муниципаль районы Калатау торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (Грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сүүткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 60 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 34 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 34 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Калатау торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2023 нче елда Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Калатау торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә

буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- 1) ТР Саба муниципаль районы Калатау торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (Грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү), карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Юлбат авыл
җирлеге башлыгы Т.Р. Шәмсиев